| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**Алькеевского**<br>**муниципального района** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әлки**<br>**муниципаль районы**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Базарлы Матак авылы** **КАРАР**

2022 елның 18 августы 305№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 июнендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 256 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 15 июнендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 566 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 июнендәге 256 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә (2022.03.02, 37№ яңа ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1бүлекнең 2 пунктындагы 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Төп хезмәт хакы (төп вазыйфаи оклад), хезмәт хакының төп ставкасы - минималь хезмәт хакы (вазыйфаи оклад), эшче һөнәре буенча һөнәри эшчәнлек башкаручы дәүләт яки муниципаль учреждение хезмәткәренең яки компенсация, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, тиешле профессиональ квалификация төркеменә керүче хезмәткәрнең хезмәт хакы ставкасы.»

1бүлекнең 2 пунктындагы 4 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Оклад (вазыйфаи оклад) - компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи)

бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең хезмәтенә түләүнең беркетелгән күләме.»

VI бүлекнең 14.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.3. Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 597 номерлы Әмере белән билгеләнгән гомуми белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булган очракта бер тапкыр түләнә торган түләүләр башкарыла, күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме гомуми белем бирү учреждениеләренең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә башкарган эш сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6. Гомуми белем бирү учреждениесенең җитәкче урынбасарына, баш хисапчыга башкарган эш сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр эшчәнлекләренең локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарына, баш хисапчыга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга кызыксындыру характерындагы түләүнең иң чик дәрәҗәсе гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләренең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.»;

күрсәтелгән карар белән расланган Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

V бүлекнең 13.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.3. Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 597 номерлы Әмере белән билгеләнгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләү тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үтәлә торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесенә, эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесенә кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең җитәкче урынбасарына, баш хисапчыга башкарган эш сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр эшчәнлекләренең локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарына, баш хисапчыга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга кызыксындыру характерындагы түләүнең иң чик дәрәҗәсе мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләренең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.»;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

VI бүлекнең 7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 1 июнендәге «2012-2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең милли стратегиясе турында» 761 номерлы Әмере белән билгеләнгән өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләү тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме өстәмә белем бирү учреждениесенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үтәлә торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр өстәмә белем бирү учреждениесе җитәкчесенә, эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6. Өстәмә белем бирү учреждениесенең җитәкче урынбасарына, баш хисапчыга башкарган эш сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр эшчәнлекләренең локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү учреждениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарына, баш хисапчыга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга кызыксындыру характерындагы түләүнең иң чик дәрәҗәсе өстәмә белем бирү учреждениесе җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләренең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2022 елның 1 августыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: Р.Х. Морадымов